ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

22.10.2025 г. Казань № 249-1/нпс-2025

2026 елга Татарстан Республикасы территориясендә җир кишәрлекләренә карата кадастр эшләренә иң чик максималь бәяне билгеләү турында

«Кадастр эшчәнлеге турында» 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15.06.2010 ел, № 468 карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 09.08.2023 ел, № 109-3/нпс-2023 карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә кадастр эшләренә иң чик максималь бәяләрне һәм торак фондын техник инвентаризацияләүгә ставкалар билгеләү тәртибе, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 22.10.2025 ел, № 20-ПР беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару, үз ихтыяҗлары өчен гаражлар төзү яисә индивидуаль торак төзелеше өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә һәм мондый җир кишәрлекләрендә урнашкан күчемсез мөлкәт объектларына карата Татарстан Республикасы территориясендә кадастр эшләренә максималь чик бәяне 12 719 сум күләмендә билгеләргә (өстәмә хак салымын исәпкә алып).

2. Билгеләргә:

кадастр эшләренә иң чик максималь бәя оештыру-хокукый рәвешләрдә Татарстан Республикасы территориясендә кадастр эшләрен башкаручы барлык юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар тарафыннан кулланыла;

бәя максималь дәрәҗәдә чик булып тора һәм кадастр эшләрен башкаручы юридик зат яисә шәхси эшкуар ихтыяры буенча төшерелергә мөмкин;

кадастр эшләренең максималь иң чик бәясе бер җир кишәрлегенә исәпләнгән һәм кадастр эшләре өчен гражданнар (физик затлар) түләгәндә кулланыла;

кадастр эшләренең нәтиҗәсе булып ызанлау планы тора.

3. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән иң чик максималь бәя 2026 елның 1 гыйнварыннан 2026 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис Р.В.Гайнетдинов